**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# Об отмене карантина, установленного на территории деревни Аман-Ошторма Кукморского района Республики Татарстан и на отдельных территориях Республики Татарстан в связи с их неблагополучием по заболеванию бешенством животных

В связи с истечением двух месяцев со дня последнего случая заболевания животных бешенством и выполнением противоэпизоотических и профилактических мероприятий, в соответствии со статьей $3^1$ Закона Российской Федерации от 14 мая 1993 года № 4979-I «О ветеринарии» **постановляю**:

1. Отменить карантин, установленный в связи с неблагополучием по заболеванию бешенством животных:

а) на территории деревни Аман-Ошторма Кукморского района Республики Татарстан;

б) на следующих отдельных территориях Республики Татарстан:

улица Хайруллина в селе Сухие Курнали Алексеевского района;

улица Молодежная в селе Кугунур Балтасинского района;

улица Товарищеская в городе Нурлате;

улица Валиуллина в поселке городского типа Богатые Сабы Сабинского района;

часть территории, используемой крестьянским (фермерским) хозяйством «Зиятдинов Р.Г.» для содержания крупного рогатого скота, у села Завод-Нырты Сабинского района;

часть территории, используемой крестьянским (фермерским) хозяйством «Насибуллин М.И.» для содержания лошадей, у деревни Чабки-Сабы Сабинского района;

откормочный цех, используемый обществом с ограниченной ответственностью «Сельскохозяйственное предприятие «Нырты» для содержания крупного рогатого скота, у села Большие Нырты Сабинского района.

2. Признать утратившими силу подпункт «а», абзацы второй – пятый, седьмой – девятый подпункта «б» пункта 1 Указа Президента Республики Татарстан от 6 марта 2015 года № УП-249 «Об установлении карантина на территории деревни Аман-Ошторма Кукморского района Республики

Татарстан и на отдельных территориях Республики Татарстан в связи с их неблагополучием по заболеванию бешенством животных».

3. Настоящий Указ вступает в силу со дня его подписания.

**Временно исполняющий обязанности Президента Республики Татарстан** **Р.Н. Минниханов**

АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН * ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
ГОМУМИ БҮЛЕК

Казань,Кремль
14 мая 2015 года
№ УП-445

**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# Татарстан Республикасы Кукмара районының Аман-Оштырма авылы территориясендә һәм Татарстан Республикасының аерым территорияләрендә терлекләр котыру авырулы булганга, аларның иминлексезлеге сәбәпле кертелгән карантинны бетерү турында

Терлекләрнең котыру белән чирләвенең соңгы очрагыннан соң ике ай узуы, эпизоотиягә каршы һәм профилактик чаралар уздырылу белән бәйле рәвештә, «Ветеринария турында» 1993 елның 14 маендагы 4979-I номерлы Россия Федерациясе Законының $3^1$ статьясы нигезендә **карар бирәм:**

1. Терлекләр котыру авырулы булганга, аларның иминлексезлеге сәбәпле кертелгән карантинны бетерергә:

а) Татарстан Республикасы Кукмара районының Аман-Оштырма авылы территориясендә;

б) Татарстан Республикасының түбәндәге аерым территорияләрендә:

Алексеевск районының Коры Көрнәле авылындагы Хәйруллин урамы;

Балтач районының Куныр авылындагы Яшьләр урамы;

Нурлат шәһәрендәге Товарищеская урамы;

Саба районының Байлар Сабасы шәһәр тибындагы поселогының Вәлиуллин урамы;

Саба районының Завод-Нырты авылы янындагы «Зыятдинов Р.Г.» крестьян (фермер) хуҗалыгы тарафыннан мөгезле эре терлек асрау өчен файдаланыла торган территориянең бер өлеше;

Саба районының Чәбки-Саба авылы янындагы «Насыйбуллин М.И.» крестьян (фермер) хуҗалыгы тарафыннан ат асрау өчен файдаланыла торган территориянең бер өлеше;

Саба районының Олы Нырты авылы янындагы «Нырты» авыл хуҗалыгы предприятиесе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан мөгезле эре терлек асрау өчен файдаланыла торган симертү цехы.

2. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Кукмара районының Аман-Оштырма авылы территориясендә һәм Татарстан Республикасының аерым территорияләрендә терлекләр котыру авырулы булганга, аларның иминлексезлеге сәбәпле карантин кертү турында» 2015 елның 6 мартындагы ПУ-249 номерлы Указының 1 пункты «а» пунктчасы,

«б» пунктчасының икенче-бишенче, җиденче-тугызынчы абзацлары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты вазыйфаларын вакытлыча башкаручы** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ • АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан,Кремль
2015 ел, 14 май
№ ПУ-445